КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2023 ел, 1 июнь

г.Казань

№ 671

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы СПИДка каршы көрәш буенча ведомствоара комиссия турындагы нигезләмәне һәм аның составын раслау турында» 2001 ел, 11 сентябрь, 635 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы СПИДка каршы көрәш буенча ведомствоара комиссия турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы СПИДка каршы көрәш буенча ведомствоара комиссия турындагы нигезләмәне һәм аның составын раслау турында» 2001 ел, 11 сентябрь, 635 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 5 сентябрь, 438 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы СПИДка каршы көрәш буенча ведомствоара комиссия турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволарының, Татарстан Республикасы шәһәрләре һәм районнары администрацияләренең, предприятиеләр, учреждениеләрнең» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендәге җирле үзидарә органнарының» сүзләренә алмаштырырга;

1.5 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты указларына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе указларына» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктта:

өченче абзацта «Татарстан Республикасы министрлыклары һәм ведомстволары, Татарстан Республикасы шәһәрләренең һәм районнарының дәүләт идарәсе органнары, предприятиеләр» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «Татарстан Республикасы шәһәрләре һәм районнары администрацияләре каршындагы СПИДка каршы көрәш буенча ведомствоара комиссияләр» сүзләрен «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендәге җирле үзидарә органнарының СПИДка каршы көрәш буенча ведомствоара комиссияләр» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктның дүртенче абзацында «Татарстан Республикасы шәһәрләре һәм районнары администрацияләре» сүзләрен «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктта:

икенче абзацта «Татарстан Республикасы министрлыкларыннан һәм ведомстволарыннан, Татарстан Республикасы шәһәрләренең һәм районнарының дәүләт идарәсе органнарыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарыннан, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарыннан» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «министрлыклар һәм ведомстволар» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин